ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.10.2022 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2841**

Муниципаль мәдәният һәм спорт учреждениеләренә бушлай йөрү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү һәм ярдәм итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 18 яшькә кадәрге балаларга һәм мобилизацияләнгән гражданнар гаилә әгъзасын озатучы 1 өлкән кешегә муниципаль мәдәният һәм спорт учреждениеләренә, кушымтага ярашлы рәвештә, бушлай керү хокукы бирелә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затлар тарафыннан муниципаль мәдәният һәм спорт учреждениеләренә бару өчен билетларны тиешле учреждение кассасында, чарага кадәр биш көннән дә соңга калмыйча, бушлай алырга мөмкин. Билетлар тиешле белешмә яки башка раслый торган документ күрсәтелгәндә бирелә.

Музей учреждениеләрендә яки урыннар буенча утырту каралмаган чараларга билетлар шулай ук килгән көнне бирелергә мөмкин. Алдан мөрәҗәгать итү вакыты билгеләнми.

3. Муниципаль мәдәният һәм спорт учреждениеләренә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затлар өчен тиешле билетлар квотасы булуын тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д. В. Лулаковка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын вакытлыча башкаручы А.В.Старостин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022
елның 21 октябрендәге 2841
нмерлы карарына
кушымта

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган мобилизацияләнгән гражданнарның 18 яшькә кадәрге балаларына бушлай йөрүне тәэмин итә торган муниципаль мәдәният учреждениеләре исемлеге

1. Зеленодольск муниципаль районының «Район мәдәният координация-методика үзәге»» муниципаль бюджет учреждениесе
2. «Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениесе
3. «Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе
4. «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе
5. «Әйшә үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесе
6. «Идел аръягы» үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесе
7. «Сәнгать галереясе» муниципаль бюджет учреждениесе
8. «Зеленодольск муниципаль районы музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе
9. «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе
10. «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе
11. «Зеленодольск балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе
12. «Васильево балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе
13. ТР ЗМР «Олимпия резервының 1НЧЕ СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
14. ТР ЗМР Васильево «2 НЧЕ СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
15. ТР ЗМР «3НЧЕ СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
16. ТР ЗМР «4НЧЕ СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
17. ТР ЗМР «5НЧЕ СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
18. ТР ЗМР «6НЧЫ СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
19. ТР ЗМР «7НЧЕ СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
20. ТР ЗМР «Көрәш СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
21. ТР ЗМР «Ледокол» СПОРТ МӘКТӘБЕ» муниципаль бюджет учреждениесе
22. «ТР ЗМР Метеоры» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном оешмасы